| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.03.2017 Казан шәһәре № под-448/17

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештырган шәхси оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләрнең белем бирүгә тоткан чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 9 март, 132 нче карарын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештырган шәхси оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләрнең белем бирүгә тоткан чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 9 март, 132 нче карарын тормышка ашыру максатыннан б о е р а м:

1. Тәкъдим ителгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында гариза формасы;

шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә яшьтәге төркемнәр буенча, шәхси эшмәкәрләргә субсидия күләмен исәпләү өчен форма;

шәхси гомуми белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр буенча субсидия күләмен исәпләү өчен форма.

2. Планлаштыру һәм хезмәткә түләү бүлегенә (В. Р. Садыйкова), боерык кабул ителгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И. Р. Мөхәммәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-
министры урынбасары – министр Э.Н.Фаттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
“___”___________2017 № под-448/17
боерыгы белән

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры
______________________(Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында

ГАРИЗА

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештырган шәхси оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләрнең белем бирүгә тоткан чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 9 март, 132 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүегезне үтенәм

_______________________________________________________________________

(шәхси белем бирү оешмасының тулы исеме, шәхси эшмәкәр)

__________________20 ел

Шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр турында мәгълүматлар

| | |
|---|---|
| Шәхси белем бирү оешмасының, шәхси эшмәкәрнең тулы исеме | |
| Юридик затның, шәхси эшмәкәрнең адресы | |
| Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыннарының адреслары | |
| Шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр телефоны | |

| | |
|---|---|
| Электрон почта | |
| Шәхси белем бирү оешмасы җитәкчесе, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме<br>Телефон | |
| Баш хисапчының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)<br>Телефон | |
| Шәхси белем бирү оешмасының, шәхси эшмәкәрнең ИНН/КПП | |
| ОГРН | |
| исәп-хисап счеты номеры, субсидия күчерү өчен банк реквизитлары | |

Ризалык бирәм:

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртү һәм кулланырга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыруга.

Гаризага теркәлә торган документлар исемлеге:

| № п/п | Документ исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Раслыйм:

гаризага теркәлә торган документларда булган мәгълүмат дөрес булуын;

шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә

аларны үтәү вакыты килеп җиткән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары юк;

шәхси белем бирү оешмасының, шәхси эшмәкәрнең Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына срогы чыккан бурычы юк;

шәхси белем бирү оешмасы чит ил юридик заты булып саналмый, шулай ук устав  капиталында  катнашучы теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган дәүләтләр һәм территорияләрдә  финанс операцияләре үткәргәндә алар турында мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган чит ил юридик затларының өлеше 50% тан артмый;

шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны, хезмәт өчен түләү, дәреслекләр һәм уку әсбаплары, укыту чаралары, уеннар, уенчыклар сатып алу чыгымнарын (биналарны карап тоту һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә киткән чыгымнардан тыш) каплау максатларында акча алмый;

шәхси белем бирүоешмасына, шәхси эшмәкәргә карата оешманы тарату, әүгәртеп кору, банкротка чыгару проөедуралары кулланылмый;

шәхси белем бирү оешмасы, шәхси эшмәкәр хуҗалык эшчәнлеген алып баруга чикләнмәгән.

Гаризаны карауга кабул итү турында яисә аны карауга алудан баш тарту турында белдерүне, шулай ук министрлык тарафыннан субсидия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында Карар кабул итү турында белдерүне, бүтән

карарларны, хатларны почта адресы яки электрон почта аша җибәрүегезне сорыйм:

______________________________________________________________________

________________________________________________________________

(юнәлеш ысулын, адресын күрсәтергә)

Баш хисапчы (булганда) ___________________________________________

(имза) Ф. И. О. (атасының исеме - булган очракта)

Шәхси белем бирү оешмасы җитәкчесе,

шәхси эшмәкәр ____________________________________________

(имза) Ф. И. О. (атасының исеме - булган очракта)

______________

(дата) М.П.